РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«26» июля 2019 г. г. Альметьевск № 158

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2015 елның 16 июнендәге «Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре милкендә булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ия булу һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мелкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында»гы 184 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм Әлмәт муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзи торган оешмаларга мелкәти ярдәм күрсәтү максатларында 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» №209-ФЗ Федераль закон, 2018 елның 3 июлендәге «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтүне киңәйтү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» №185-ФЗ Федераль закон нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2015 елның 16 июнендәге «Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре милкендә булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ия булу һәм (яки) файдалануга тапшыру өчен билгеләнгән муниципаль мелкәт исемлеген формалаштыру, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында»гы 184 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре милкендә булган муниципаль мөлкәт исемлеген, хокукка ия өченче заттан тыш (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мелкәти хокукларыннан тыш), шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак төзелешен алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш), кече һәм урта

Зак. № 3223

эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тезү, алып бару һәм бастырып чыгару тәртибен расларга (1 нче кушымта)»;

1.2. 1 нче кушымта исемендә «җир кишәрлекләреннән тыш» «сүзләрен тешереп калдырырга, «(кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш)» сүзләрен «(хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек хокукларыннан тыш), шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак тезелешен алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 1 нче «Гомуми нигезләмәләр» бүлегендәге 1.1 пунктындагы "җир кишәрлекләреннән тыш» сүзләрен тешереп калдырырга, «(кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мелкәти хокукларыннан тыш)» сүзләрен «(хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мелкәти хокукларыннан тыш), шул исәптән җир кишәрлекләрен (шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак тезелешен алып бару ечен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш) сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 1 нче «Гомуми нигезләмәләр» бүлегендәге 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2008 елның 22 июлендәге «Дәүләт яисә муниципаль милектә булган һәм арендалана торган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары милкендә булган күчемсез мелкәтне алу үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әлеге мөлкәтне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары милкенә түләүсез читләштерүдән тыш, һәм Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктының 8 һәм 9 пунктлары очракларында исемлеккә кертелгән муниципаль мелкәтне сату тыела. Әгәр субарендада 2006 елның 26 июлендәге «Конкуренцияне яклау турында» 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясындагы 1 өлешенең 14 пунктында каралган мелкәт бирелә икән, күрсәтелгән мелкәткә карата шулай ук алардан файдалану хокукларын яңадан алу, алардан файдалану хокукын залогка тапшыру һәм мондый мелкәттән файдалану хокукын теләсә кайсы хуҗалык эшчәнлегенең башка субъектларының устав капиталына кертү, мондый мөлкәтне арендалау килешүләре буенча хокукларны һәм бурычларын еченче затларга тапшыру (яңадан рәсмиләштерү), мондый мелкәтне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына тапшыру, мондый мелкәтне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын тезүче оешмалар тарафыннан субарендага тапшырудан тыш, субарендага тапшыру тыела.;

1.5. «Исемлекне формалаштыру тәртибе» 2 нче бүлегендәге 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән муниципаль мелкәт саныннан исемлек тезелә. (Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык, шәхси торак тезелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш). Исемлеккә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына арендага бирелгән җир кишәрлекләреннән тыш, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 статьясындагы 8 пунктның 1-10, 13-15, 18 һәм 19 пунктчаларында каралган җир кишәрлекләре кертелми;

1.6. "Исемлекне формалаштыру тәртибе» 2 нче бүлегендәге 2.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Исемлеккә биналар (корылмалар), торак булмаган биналар, еченче затлар хокукларыннан ирекле (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының милек

хокукларыннан тыш) кертелә, шулай ук корылмалар, җиһазлар, махсуслаштырылган транспорт чаралары (үзйөрешле машиналар) кертелергә мөмкин.

Муниципаль унитар предприятиегә хуҗалык алып бару хокукында, муниципаль учреждениегә оператив идарә хокукында күрсәтелгән предприятие яки учреждение тәкъдиме белән һәм Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты ризалыгы белән беркетелгән муниципаль милек кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга мондый мөлкәт бирү максатларында исемлеккә кертелергә мөмкин»;

1.7. "Исемлекне алып бару тәртибе» 3 нче бүлегендәге 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Исемлек түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган реестрдан гыйбарәт:

- тәртип буенча номер;
- милекнең реестр номеры (җир участогы);
- объектның исеме;
- мелкәтнең (җир кишәрлегенең) идентификацион мәгълүматлары (кадастр номеры һәм тдп.);
- милек (җир участогы) характеристикалары (мәйданы, озынлыгы һәм тдп.);
- муниципаль күчемсез мөлкәт (җир кишәрлеге) урнашкан урын);
- милекнең максатчан билгеләнеше (әгәр милек төрле максатчан билгеләнеше буенча кулланылырга мемкин булса, исемлектә аны куллануның мемкин булган барлык очраклары да күрсәтелә), җир кишәрлеге ечен рөхсәт ителгән файдалану тере күрсәтелә;
- милекне (җир кишәрлеген) чикләү (йөкләү) турында мәгълүмат».

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлек мәсьәләләре буенча шәһәр Советының даими комиссиясенә йөкләргә (Хәйруллин И. Р.).

Шәһәр башлыгы урынбасары А.М. Токарев